КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 март г.Казань № 287

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 май, 431 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 май, 431 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 май, 311 нче; 2017 ел, 6 декабрь, 938 нче; 2019 ел, 21 сентябрь, 863 нче; 2020 ел, 3 август, 645 нче; 2021 ел, 20 сентябрь, 885 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктта «, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибендә:

исемендә «, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.1 пунктта «, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган, Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре (алга таба – халыкны эш белән тәэмин итү үзәге) юлламасы буенча һөнәри укыган яки өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, төзелә торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда Татарстан Республикасы бюджет акчасы исәбеннән бер тапкыр финанс ярдәме (алга таба – эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр финанс ярдәме) күрсәтү механизмын билгели.»;

1.2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2.1. Эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык итү максатларында эшсез гражданнарга бирелә.»;

1.2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2.2. Эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре күләме һәм тиешле финанс елына субсидияләр бирүгә бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.»;

II бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү шартлары, күләме һәм тәртибе»;

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыру өчен Тәртип нигезендә халыкны эш

белән тәэмин итү үзәкләренең эшсез гражданнарына, граждан тарафыннан әлеге максатлар өчен бизнес-планны тормышка ашыруга каралган акча суммасыннан кимендә 5 процент күләмендә, ә ике һәм аннан күбрәк граждан тарафыннан юридик зат оештырылган (гамәлгә куелган) очракта – аларның һәрберсе әлеге күләмдә үз акчасын кертү шарт белән, 145 100 сум күләмендә бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтелә.

Эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыру өчен бер тапкыр күрсәтелә торган финанс ярдәме эшсез гражданнарга бер мәртәбә бирелә.»;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме 18 яше тулган һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Эшсез гражданнарның үзмәшгульлегенә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (эшсез дип билгеләнгән тәртиптә танылган гражданнарга һәм эшсез дип билгеләнгән тәртиптә танылган, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри укуда булган һәм өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга аларны юридик зат, индивидуаль эшмәкәр яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы буларак дәүләт теркәвенә алганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алганда документларны әзерләү өчен бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтүне кертеп) федераль дәүләт стандартын раслау турында» 2013 елның 24 декабрендәге 773н номерлы боерыгы белән расланган Эшсез гражданнарның үзмәшгульлегенә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (эшсез дип билгеләнгән тәртиптә танылган гражданнарга һәм эшсез дип билгеләнгән тәртиптә танылган, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри укуда булган һәм өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга аларны юридик зат, индивидуаль эшмәкәр яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы буларак дәүләт теркәвенә алганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алганда документларны әзерләү өчен бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтүне кертеп) дәүләт стандартында каралган тәртиптә эшсез гражданнарның эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү нәтиҗәләре буенча индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алу, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алу, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алу, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә кую юлы белән эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында тәкъдимнамәләрдән гыйбарәт бәяләмә алган эшсез гражданнарга күрсәтелә.»;

2.3 һәм 2.4 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

2.9 пунктның алтынчы абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

2.16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.16. Тәртипнең 2.5 һәм 2.8 пунктларында күрсәтелгән эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында гариза, шартнамә, карарлар формаларын Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан раслана.»;

2.17 пунктта «алып бару» сүзләрен «гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга.

3.1 пунктта «һәм документларны әзерләүгә бер тапкыр финанс ярдәме» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.2 пунктта татар текстында «дәүләт теркәвенә алганда бер тапкыр финанс

ярдәме һәм документлар әзерләүгә» сүзләрен «эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыруга» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктта «(документларны әзерләү шартнамәсендә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.4 пунктта «һәм документларны әзерләүгә бер тапкыр финанс ярдәме» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге Тәртипкә кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибенә кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 29 март, 287 нче
карары редакциясендә)

Форма

Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү нәтиҗәсенә ирешү турында
хисап

| Нәтиҗәнең исеме | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификациясе буенча үлчәү берәмлеге | | Нәтиҗәнең план буенча мәгънәсе | Хисап датасы хәленә карата нәтиҗәнең ирешелгән мәгънәсе | Нәтиҗәнең план буенча мәгънәсен үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | исеме | коды | | | | |
| Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алган, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алган, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алган, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйган көннән кимендә 12 ай эчендә бизнес-план нигезендә эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру | ай | 366 | 12 | | | |

_____________________ (җитәкченең вазыйфасы) _____________________ (җитәкченең, индивидуаль эшмәкәрнең имзасы, Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда)
М.У. (булганда)

Баш бухгалтер _________________ (имзасы) _________________________________ (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

20__ ел, «___» ___________

_________________________